# ХӘЕРЛЕ КӨН!

















# АНТОНИМНАР ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ:

- ***Күренешләрнең, предметларның, кешеләрнең сыйфатларын тасвирлыйлар:*** ***ак – кара, чиста – пычрак, юмарт – саран.***
- ***Вакыт төшенчәсен белдерәләр:*** ***көн – төн, быел – былтыр.***
- ***Күренешләрнең озынлыгын, күләмен ачыклый:*** ***аз – мул, озын – кыска, якын – ерак, ас - өс, киң – тар, югары – түбән.***
- ***Табигать күренешләрен күрсәтәләр:*** ***җылы – салкын, җир – су, аяз –болытлы, коры – юеш, сай – тирән.***
- ***Процессларны каршы куялар:*** ***бару – кайту, яту – тору, кыскару – озынаю, чыгу – керү, арту – кимү.***

# ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ АНТОНИМНАР

- ***Атадан*** *күреп* ***ул*** *үсә -* ***анадан*** *күреп* ***кыз*** *үсә.*
- ***Надан*** *булып* ***туалар****,* ***галим*** *булып* ***үләләр****.*
- ***Каланың зурын****,* ***авылның кечесен*** *макта.*
- ***Ялкаулыктан авырырсың****,* ***тырышлыктан савыгырсың****.*
- ***Аз сөйлә****,* ***күп тыңла****.*
- ***Ахмак бирер****,* ***акыллы алыр****.*
- ***Белемсез дустыңнан белемле дошманың*** *артык.*
- ***Бер ялган мең хакыйкатьне*** *боза.*
- ***Яманлыкны азсынма, яхшылыкны күпсенмә****.*

# ТАБЫШМАКЛАР

**Ул булса, көн була**
**Ул булмаса, төн була.**
**(*Кояш*)**

**Көзен туа, язын үлә.**
**(*Боз*)**

**Канатсыз оча,аяксыз чаба.**
**Тышта өелә,өйдә җәелә.**
**(*Кар*)**

**Ятты-ятты да елгага карап чапты.**
**(*Кар*)**

**Күктән килде,**
**җиргә китте.**
**(*Яңгыр*)**

# ӘДӘБИ ӘСӘР ИСЕМНӘРЕНДӘ АНТОНИМНАР

- “Сугыш һәм солых” (Л.Н.Толстой)
- “Аталар һәм балалар” (И.С.Тургенев)
- “Исәннәр һәм үлеләр” (К.Симонов)
- “Мәкер һәм мәхәббәт” (Ф.Шиллер)
- “Ут һәм су” (Ә.Баянов)
- “Яшәү белән үлем арасында” (Н. Дәүли)
- “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят” (А.Гыйләҗев)
- “Ана һәм кыз” (Ә.Еники)
- “Бикбатыр белән Бикуркак” (А.Алиш)

# АНТОНИМНАР

-Капма каршы мәгънәле сүзләр.

-Бер сүз төркеменә кергән сүзләр.

-Исем, сыйфат, рәвеш, фигыльдә күбрәк очрыйлар



Антонимнарның сүзтезмә булып килүе **оксюморон** дип атала. Антономик мөнәсәбәткә корылган стилистик чара; мәгънәләре белән логик каршылыклы **сүзләрнең** ярашып, бер **сүз** тезмәсе хасил итүе.

# АНТОНИМНАР НИ ӨЧЕН КУЛЛАНЫЛА?

- **Сөйләмгә серлелек өстәү һәм гомумиләштерү өчен.**

  *Акка кара тиз йога .Иске авыздан яңа сүз.*

- **Уй – фикерне читләтеп әйтү өчен.**

  *Ачы белән төзәтәләр, татлы белән бозалар*

- **Сөйләмнең көчен, сәнгатьлелеген арттыру өчен.**

  *Күп исле гөлләр арасында*

  *Бер иссез гөл исле булган.*

  *Күп иссез гөл арасында*

  *Бер исле гөл иссез калган.*

- **Әйберләрне, күренешләрне чагыштыру, каршы кую өчен**.

  *Гыйлемсез- бер яши, гыйлемле мең яши.*



# ӨЙ ЭШЕ:

АНТОНИМНАР КУЛЛАНЫП БЕРӘР ӘДӘБИ ГЕРОЙГА ХАРАКТЕРИСТИКА ЯЗЫП КИЛЕРГӘ



**Мәкаль**

**Омоним**

**Ләкин**

**Оксюморон**

**Дәрдман**

**Елга**

**Циркуль**



# ДӘрес тӘмам, сау-булыгыз!

Күңел күкләрегез аяз булсын!

